КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 март г.Казань № 265

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм стажировкалауга «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең гранты турында» 2021 ел, 26 июль, 646 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм стажировкалауга «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең гранты турында» 2021 ел, 26 июль, 646 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Министрлык, сайлап алуны үткәрү датасына кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары программасының рәсми сайтында

(www.alga.tatarstan.ru) (алга таба – грантның рәсми сайты), түбәндәге мәгълүматны күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыруны тәэмин итә:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Нигезләмәнең 4.19 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Нигезләмәнең 4.12 пункты, 4.13 пунктларындагы икенче – унынчы абзацлары нигезендә грант алуга дәгъва итүчеләргә карата таләпләрне һәм грант алуга дәгъва итүчеләр тарафыннан әлеге таләпләргә туры килүне раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Нигезләмәнең 4.5 – 4.13 пунктлары нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Нигезләмәнең 4.14 – 4.17 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләрен;

сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен грант алуга дәгъва итүчеләргә аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм грантның рәсми сайтында, сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасын.»;

Министрлык, җиңүчеләр исемлеге расланган датадан җиде көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм грантның рәсми сайтында түбәндәгеләрне үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасын, вакытын һәм урынын;

заявкаларын бәяләү датасын, вакытын һәм урынын;

заявкалары карап тикшерелгән грант алуга дәгъва итүчеләр турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән грант алуга дәгъва итүчеләр турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

заявкаларны бәяләү эзлеклелеге, заявкаларны тәкъдим итүләрне бәяләүнең күздә тотылган һәр критерие буенча заявкаларга бирелгән күрсәткечләр, заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә заявкаларга тәртип саннарын бирү турында кабул

ителгән карарны;

килешү төзелә торган грант алучының исеме һәм аңа бирелә торган грантның күләме.»;

4.10 пунктның унөченче абзацында «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

4.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. «Югары белем бирү мәгариф оешмалары» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүче «Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли торган югары белем бирү мәгариф оешмасы булып тора» дигән сайлап алу критериенә туры килергә тиеш.

«Югары белем бирү мәгариф оешмалары» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүче сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1енче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

бу Нигезләмәдә күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмаска тиеш.

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмаска тиеш;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

үзгәртеп оештыру (грант алуга дәгъва итүчегә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәскә, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаска тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма

орган функциясен үтәүче зат яки грант алуга дәгъва итүченең баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмаска тиеш;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш;

чакырылган Россия һәм (яки) чит ил мөгаллименең һөнәри, фәнни һәм (яки) академик казанышлары турында презентациясе булырга тиеш.

«Югары белем бирү мәгариф оешмалары» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчене сайлап алуда катнашу өчен түбәндәге документлар исемлеген тапшырыла:

бу Нигезләмәнең 5 нче кушымтасы нигезендә форма буенча заявка;

гамәлгә ашырыла торган белем бирү программасы өчен әһәмиятен күрсәтеп, Россия яки чит ил мөгаллимен, тикшеренүчесен яки практика үтүчесен чакыру кирәклеген нигезләү;

белем бирү эшчәнлеген алып баруга лицензия күчермәсе;

дәүләт аккредитациясе турында таныклык күчермәсе;

грант алуга дәгъва итүченең бу пункттагы өченче – тугызынчы абзацларда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган, грант алуга дәгъва итүченең җитәкчесе тарафыннан имзасы куелган мәгълүмати белешмә кәгазе;

белем бирү хезмәтләре күрсәтү өчен җәлеп итәргә планлаштырыла торган Россия яки чит ил мөгаллимнәренең, тикшеренүчеләренең яки практика үтүчеләренең рәсми чакыру кәгазе күчермәсе;

чакырыла торган Россия яки чит ил мөгаллиме, тикшеренүчесе яки практика үтүчесе катнашында белем бирү программасын гамәлгә ашыру планы (чакыруның максатлары һәм сроклары күрсәтелә);

белем бирү программасын гамәлгә ашыруга чыгымнар сметасы;

чакырылган мөгаллим тарафыннан лекцияләр уку планлаштырылган белем бирү программасының уку-укыту планы күчермәсе;

цитаталаштыру индексын, мөгаллим яки фәнни эш стажын, эшләгән белем бирү ресурслары санын, рус теленә тәрҗемә белән укыту-методик ярдәмлекләрен күрсәтеп, чакырыла торган Россия яки чит ил мөгаллиме, тикшеренүчесе яки практика үтүчесенең резюмесы;

чакырыла торган Россия яки чит ил мөгаллиме, тикшеренүчесе яки практика үтүчесенең рәсми ризалыгы;

грант алуга дәгъва итүче тарафыннан грант бирү максатларына чыгымнарның гомуми суммасыннан кимендә 20 процент күләмендә финанслашуны тәэмин итү турында гарантия хаты.»;

5.2 пунктта:

бишенче абзацта «нәтиҗәләргә» сүзен «нәтиҗәләр күрсәткечләренә» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткечләре (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант операторының, грант операторы белән (дәүләт (муниципаль) унитар

предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант операторының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы турында шарт;»;

сигезенче абзацта «, максатларын» сүзен төшереп калдырырга;

6.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югары белем бирү мәгариф оешмалары» категориясе буенча грант алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр һәм хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып грант торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап;

белем бирү программасы гамәлгә ашырылган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә, белем бирү программасын гамәлгә ашыруны раслый торган документларны, белем бирү программасын уңышлы гамәлгә ашыру турында иҗади хисапны теркәп, белем бирү программасында катнашкан укучыларның саны күрсәтеп, бу Нигезләмәнең 4.19 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләр күрсәткечләренә ирешү турында хисап.»;

6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Министрлык грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне башкара.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Грант бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешүдән һәм грант бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Грант биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган очракта, бу Нигезләмәнең 4.19 пунктында билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, шулай ук грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшырылмаган очракта, хисап бирү сроклары бозылган очракта, грант алучы Министрлыкның язма таләбен алган көннән 30 календарь көн эчендә грантны тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтара.»;

әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасындагы 8.1 пунктының 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затларга, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затларына (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) карамый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый»;

әлеге карар белән расланган Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын бирү буенча республика комиссиясе составында:

«Яшь белгечләр», «Укытучылар һәм фәнни хезмәткәрләр», «Югары белем бирү мәгариф оешмалары» категорияләре буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссиядән И.Р.Гафуровны чыгарырга;

«Мәгариф оешмалары хезмәткәрләре» категориясе буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссиядән Ю.П.Прохоровны чыгарырга;

«Проект төркемнәре» категориясе буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия составыннан А.В.Савваны, А.А.Федоровны чыгарырга;

«Яшь белгечләр», «Укытучылар һәм фәнни хезмәткәрләр», «Югары белем бирү мәгариф оешмалары» категорияләре буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия составына Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы рәисе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе Ленар Ринат улы Сафинны (килешү буенча) кертергә;

«Яшь галимнәр», «Ике дипломлылар» категорияләре буенча грант алуга дәгъва итүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия составына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге баш киңәшчесе Александра Анатольевна Шинкаренконы кертергә;

«Мәгариф оешмалары хезмәткәрләре» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләренең Татарстан Республикасындагы һөнәри берлеге төбәк оешмасы рәисе Ирина Николаевна Проценконы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге баш киңәшчесе Александра Анатольевна Шинкаренконы;

«Проект төркемнәре» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Родион Михайлович Карповны;

«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы директоры урынбасары (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге баш киңәшчесе Александра Анатольевна Шинкаренконы;

«WorldSkills» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия составына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге баш киңәшчесе Александра Анатольевна Шинкаренконы кертергә;

«Яшь белгечләр», «Укытучылар һәм фәнни хезмәткәрләр», «Югары белем бирү мәгариф оешмалары» категорияләре буенча грант алуга дәгъва итүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия әгъзасы Алексей Алексеевич Калачевның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге федераль дәүләт бюджет фән учреждениесе директоры (килешү буенча)»;

«Яшь галимнәр», «Ике дипломлылар» категорияләре буенча грант алуга дәгъва итүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия әгъзасы Рияз Гатаулла улы Минзариповның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе президенты (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин